*Хәкимов Р.Ф.,*
*Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИ аспиранты*

# *Тарихи җырларның татар фольклористикасында өйрәнүнең торышы*

Элек-электән халык үз башыннан кичкән хәлләргә карата үзенең фикерен, мөнәсәбәтен җырлар аша чагылдырып бирергә омтылган. Халыкның рухи тормышында җыр бик җитди урын алып тора, рифмаларга салынган берничә юлда җырлар кеше күңеленең иң нечкә хисләрен, яшәешен, аның белән булган вакыйгаларны оста һәм тирән итеп сөйләп, тасвирлап бирә алалар.

Ә иң әүвәлге чорларда исә, әле җыр жанры барлыкка килгәнче, алда саналган максатларга ирешү өчен ниндидер авазлар гына кулланылган. “Борынгыларның үзләре изге-тотем итеп санаган яки сугарлык иткән хайваннарга, кошларга охшарга, ияргергә тырышуы әлеге җанвар һәм кош-кортның гадәтләрен, хәрәкәтләрен һәм тавышларын иҗади имитацияли торган биюләр, хәтта җырлар тууына китерә һәм җыр текстларының ритмына да турыдан-туры яки бию аша үз мөһерен суга” – дип яза (1: 14).

Тарихка күз салсак, авыр заманнарда халкыбызның рухын, милли хисләрен, телен нәкъ менә җырлар яшәткән, җырлар саклап калган. Бу жанр шулай ук информация саклау һәм йөртү үзлегенә дә ия. Мондый сыйфат бигрәк тә тарихи җырларга хас, алар – кайчандыр булып узган сәяси вәзгыятьләрне, вакыйгаларны иҗтимагый-сәяси шартларның художестволы чагылдыруга, ата-бабаларыбызның тормышын күз алдына китерүче әсәрләр.

Дөрес, XX йөз башында татар халкында тарихи җырлар бөтенләй юк дигән фикерләр дә йөргән. Бу мәсьәләне беренче булып күтәргән әдип һәм галим Гали Рәхим: “Бездә тотып күрсәтерлек тарихи җырлар ... юк, чөнки “безнең һәммә җырларыбыз да лирик җырлар гына,” — дип нәтиҗә ясый (2: 22). Ә бит тарихи җырлар белән чагыштырганда, лирик җырлар бөтенләй үзгә сыйфатларга ия булып торалар. Бу төр җырлар нигезендә психологик сюжет ята, алар лирик геройның эчке кичерешләренә бәйле рәвештә барлыкка киләләр.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк: XX йөз башында бездә тарихи җырларның функциясен бәетләр башкара дип санала. Дөрестән дә, художестволы үзенчәлекләре бәетләрнеке белән якын булганлыктан, тарихи җырларның үзләренә генә жанр үзенчәлекләрен билгеләү шактый кыен. Үзенчәлекләрнең берсе шунда – тарихи җырлар фаҗигалелекне тормышчан гәүдәләндерүдә иң югары баскычта торалар. Аларда инде чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәт конркет фаҗигалеккә нигезләнә. Икенче төрле әйткәндә халыкның тарихы-аңы тормышта чыннан да булган реаль вакыйгаларга мөнәсәбәттә гәүдәләнә. Ә бәетләр исә фаҗигале эчтәлекне драматик хәлләр аша ачып бирү белән характерланалар.

Җырлардагы тарихилык Г.Тукай, Г.Рәхим, Ф.И.Урманчеев, И.Надиров, М.Бакиров, М.Нигъмәтҗәнов, А.Абдуллин, һ.б.лар тарафыннан өйрәнелде. Үз галимнәребез белән беррәттән, татар фольклорының бу жанры рус елъязмачылары һәм тарихчыларында да кысыксыну уята: Н.Ф.Катанов, В.В. Радлов, Н.И.Воробьев, А.С.Ключарев кебек рус галимнәре, тарихилык принцибына таянып, бу жанрның үзенчәлекләрен фәнни яктан ачарга тырышалар.

Беренче булып, татар фольклористикасында тарихи җыр терминын 1899 елның 23 февралендә Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә уздырылган җыелышта Н.Ф.Катанов куллана. Ул: "Казан татарларында тарихи җырлар табылуына бик шатландым, беренче ике җырны Казан татары Каюм Насыйридан, ә өченче җырны Барышев Ибраһим Исхаковтан алдым," – дип хәбәр итә (3: 4).

Галим китергән әсәрләрдә кайбер тарихи вакыйгалар булса да, монда без җырга тартым элементлар таба алмыйбыз. Хезмәт тулысынча бәетләргә багышлана, тикшеренүче бәет терминын русчага "исторические песни" дип тәрҗемә итә. Алай да моңа карап хезмәт кыйммәте кимеми, Н.Ф.Катанов тарафыннан зур теләк һәм тырышлык куелганы сизелә. Алга таба бу өлкәдә эшләүче галимнәргә бу үзенә күрә тарихи җырларны бәетләрдән аерып карарга бер этәргеч булып тора.

XX гасыр башына кадәр, татар халкының тарихи җырлары бөтенләй басылып чыкмый диярлек, басылган очракта да, алда искәртеп үткәнебезчә, күбесе бәет жанрына кертеп карала. Бу турыда Г.Рәхим: "Безнең тарихи бәетләребез башка халыкларның тарихи җырлары урынына торалар", - дип язып чыга (2:12). Ул чорда күп кенә фактик материаллар әле билгеле булмый, тикшеренүче бер эпик төрне генә өйрәнеп, берләштереп, башка жанр турында нәтиҗә ясап куя. Профессор Ф. Урманче: "Г.Рәхим ялгышы шунда ки, ул татар халкының бер эпик төркеме форлькторын өйрәнү нәтиҗәсендә туган фикерен бөтен халык иҗаты өчен дөрес булырга тиеш дип уйлый", — дип бик хаклы искәрмә ясый (4: 148). Шул рәвешле, күп еллар буе башка халыклар галимнәре, фольклорчылары арасында татар фольклорында тарихи җыр функциясен бәет башкара, дигән караш яшәп килә.

XX гасыр урталарыннан соң тарихи җыр мәсьәләсен профессор Н.И.Воробьев күтәреп чыга, ул: "Идел буе татарларында халык батырлары Пугачев, 1812 елгы Ватан сугышы турында тарихи җырлар бар," - дип яза (5: 345). Ләкин бу фикерләр текстлар белән исбатланмый. Дөрестән дә, хәзерге көндә безгә "Пугачев", "Пугачев явы", "Любизар" кебек эчтәлекләре белән Н.И.Воробьев күрсәткән вакыйгаларга караган җырлар билгеле. Авторның конкрет кайсы әсәрләрне күз алдында тотуын гына әйтүе кыен.

Музыкаль фольклор белгече М.Нигъмәтҗанов исә: "Без болгарларда халыкның үткәнен гәүдәләндерүче тарихи-эпик җырлар да булган дип нәтиҗә ясый алабыз" – дип яза, ләкин бу әсәрләрнең сакланмавын һәм безнең көннәргә килеп җитмәвен искәртә (6: 123).

Алда әйтеп кителгән галимнәребездән аермалы буларак, А.А.Абдуллин үзенең фикерләренә мисаллар биреп бара. "Себер юллары"

җырының эчтәлеге турында “патша Россиясенең татарларны Себергә көчләп күчерү, сөрү фактын, колониаль сәясәтне чагылдыра” дип күрсәтә (7: 45-46). Әмма фольклорчы Ф.И.Урманчеев: “Бу лирик җыр татар-мишәрләр арасында киң таралып, “Шәлчеләр” җырының бер варианты гына. Аның эчтәлеге бәхет, мал эзләп читтә йөрүчеләр турында сөйли. Җыр XVI-XVII йөзләргә түгел, нигездә XVIII XIX йөзләргә карый, ” – дигән төзәтү бирә.

А.А.Абдуллин “Пугачау турында” дигән әсәрне тарихи җыр да, бәет дип тә атый. Фольклорчы И.Надиров та әлеге әсәрне тарихи җырга да, бәеткә дә кертеп карый (8: 55).

1964 елда М.Мозаффаров, Ю.Виноградов, З.Хәйруллина тарафыннан әзерләнгән “Татар халык көйләре” исемле китап басыла (9: 60-66). Алда “Тарихи җырлар” исеме астында да берничә җыр бирелә. Ләкин бу әсәрләрне игътибар беләнрәк тикшерсәк, аларның берсен дә тарихи җырларга кертеп булмый, бу төргә хас элементлар монда бер дә күренми.

Алда атап үтелгән тикшеренүчеләр тарихи җыр исемен телгә алсалар да, безнеңчә, татар халкында бу жанрның булуы конкрет мисаллар белән исбатланмады. XX йөз башында күтәрелгән мәсьәләләр гасыр уртасына кадәр тулысынча ачылу таба алмады.

1969 елда, күп кенә бәхәсле фикерләргә нокта куеп, профессор Ф.И.Урманчеевның тарихи җырларга багышланган беренче күләмле мәкаләсе дөнья күрә. Галим бу жанрны мисаллар ярдәмендә дәлилләп, лирик җырлардан һәм бәетләрдән аерып күрсәтә. Теоретик билгеләмә дә беренче тапкыр аның тарафыннан әйтелә. Тик автор тарихи җырларның барлыкка килүен шактый соңгы чорларга – XVI-XVIII йөзләргә генә нисбәтләп карый. Әмма галимнең бу мәкаләсеннән соң басылып чыккан кайбер хезмәтләрендә исә тарихи җырлар инде болгар чорында ук булган дигән караш алга сөрелә. Нигездә Ф.Урманчеев бу фикерен 2005 елда дөнья күргән “Татар халык иҗаты” исемле дәреслегендә дәлилләп чыга (10: 200).

Әдәбиятчы һәм фольклорчы галим М.Бакиров та бу жанрның формалаша башлавын Болгар чоры белән бәйләп карый (11: 67). Ул үзенең фикерен XIV йөздә Болгар дәүләте тормышын чагылдырган “Болгар ятимнәре” исемле тарихи җыр белән исбатлап китә. Ләкин безнең көннәргә Болгар чорына караган мондый әсәрләрнең берничәсе генә килеп җиткән.

Башка халыкларда тарихи җырларны фәнни өйрәнү чагыштырмача алгарак киткән. Башкорт галиме С.Галинның бу халыкта тарихи җырлар барлыгын исбатланган “Йылдар һәм Йырзар” исемле хезмәте әле 1967 елда ук дөнья күрә (12: 53). Китап тулысынча башкорт тарихи җырларына багышланган. Автор җырларның тормыштагы җирлеген һәм халык тарихында тоткан урынын билгели, туу, формалашуы, үсү процессын өйрәнә. Тикшеренүче тарихи җырларның башкортларда XV гасыр башларында күренә башлавын искәртә, ә чын-чынлап формалашуын Рус дәүләте белән бәйләп карый: “Башкорт тарихи җырларының эпик жанр булып тәмам формалашуы... башкорт халкының үз ирке белән Рус дәүләтенә кушылуы белән тыгыз бәйләнгән”, - дип билгеләп үтә.

Ә татар тарихи җырларының бәетләр белән охшаш булуы турында галим: “Башкорт халык иҗатында тарихи җырлар эпик функция башкаручы төп җырлар булып формалашканнар һәм үскәннәр, ләкин татар халкының авыз-тел иҗаты исә бу жанрларны белми һәм эпик функция борын-борынын бәетләргә күчкән”, - дип яза.

Башкортлар белән татарларның охшаш фольклор әсәрләре булу бу халыкларның кардәшлек һәм күршеләр булуы бер дәүләттә яшәве нәтиҗәседер. 1812 елгы француз яуы хакындагы бәетләрдә һәм башкорт тарихи җырларда бик якын юллар очрый.

Рус халкында тарихи җырларны өйрәнү торышына килсәк, монда А.Д.Соймоновның “П.В.Кириевский и его собрание народных песен” дигән китабы аеруча зур игътибарга лаек. Хезмәт Кириевскийның тормышы белән бәйләп язылган, күбрәк аның иҗатына, материалларның җыелуына игътибар бирелгән.

Берничә елдан соң Н.А.Криничнаяның, Б.Н.Путилов редакциясендә басылып чыккан “Народные исторические песни начала XVII века” дигән хезмәтендә тарихи җырларга игътибар күбрәк бирелә, автор XVII гасыр башларын болганчык вакыт (смутное время) дип карый. Китабында ул моңа кадәр тарихи җырлар белән бәйле булган хезмәтләрен анализлый.

В.И.Чичеров, Т.М.Акимова исә рус тарихи җырларын өйрәнү чиген киңәйтәләр: солдат җырларын да, конкрет тарихи вакыйгаларга нигезләнгәнлеге өчен булса да, халык тормышын дөрес сурәтләгәне өчен тарихи җыр дип санарга мөмкин диләр.

Шул рәвешчә татар фольклористикасында тарихи җырларын өйрәнүдә сизелерлек нәтиҗәләр бар. Бу эшне тагын да дәвам итәргә, тирәнәйтергә кирәк. Моңа башкорт, рус фольклорчыларының уңай нәтиҗәләренә киң таяну зарур.

**Әдәбият**

1. Бакиров М. Шигърият бишеге // Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары / М.Бакиров. — Казан:”Мәгариф”, 2001. — Б. 22.

2. Рәхим Г. Халык әдәбиятымызга бер караш / Г.Рәхим // “Аң” – 1914. – 14 сан. — Б. 14-16.

3. Катанов Н.Ф.Исторические песни казанских татар / Н.Ф. Катанов. – Казан: Типография императорского университета, 1899. – 245 с.

4. Урманчеев Ф.И. Тарихи җырлар / Ф.И. Урманчеев // Казан утлары. – 1969. - № 3. – Б. 148-152.

5. Народы Европейской части СССР. – Мәскәү: Наука, 1964. – 675 с.

6. Нигъмәтҗанов М. Ерак чыганаклар / М. Нигъмәтҗанов // Совет әдәбияты. — 1963. – №2. – 123 б.

7. Музыкальная культура Советской Татарии. — Казань, 1959. — Б. 45-46.

8. Надиров И. Тарихи һәм лирик җырлар / И. Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 234 б.

9. Мозафаров М. Татар халык көйләре / М. Мозафаров, Ю. Виноградов, З. Хайруллина. – М., 1964. – 347 б.
10. Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2005. – 200 б.
11. Бакиров М. Үзенчәлекле жанр буларак бәетләр // Яхин А. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе / А. Яхин, М. Бакиров. — Казан, 1979.
12. Галин С. Йылдар һәм Йырзар / С. Галин. - Өфе: Башк. кит. нәшр., 1967. – 178 б.